**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Пүскән авылы торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**10 декабрь 2022 ел** **№ 2**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына карата, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге Пүскән авылы торак пунктында халык җыены **карар бирде**:

1. 2021 елның 13 декабрендә Пүскән авылы халык җыены карары белән билгеләнеп узарасалым акчасына эшләнгән «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пүскән авылында иҗтимагый-мәдәни үзәк төзелеше» объектын төзү, проект-смета документларын эшләтү һәм дәүләт экспертизасын үткәрүдән экономияләнгән 590349,57 сум күләмендәге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү – 250000,00 сум;

- юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү өчен вак таш – 340349,57сум.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен Норма авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Татарстан Республикасы мунципаль берәмлекләре порталы составындагы Балтач муниципаль районы сайтында бастыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Шарипҗанов Р.Н.